| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСАНДРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСАНДРОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Александровка авылы

2019 ел, 8 апрель №8

**Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2010 елның 2 ноябрендәге 880нче карарына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Расларга:

1.1. Капиталь төзелеш объектына (шул исәптән тәмамланмаган төзелеш) почта адресы бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Агач һәм куаклар утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Васыятьләрне раслау һәм ышанычнамәләрне раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Җир кишәрлегенә белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты, йорт биләмәләренә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә (4 нче кушымта).

1.5. Документлар күчермәләрен һәм алардан өземтәләрне таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

2. Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 маеннан 10нчы номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим

Авыл җирлеге башлыгы                                                                 И.Р. Вәлиев